ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $8^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$8^1$ статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты компетенциясе**

Татарстан Республикасы Президенты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрне региональ яисә муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләргә кертү турында карар кабул итү, Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль системасының тиешле идарә һәм көч органнары өчен югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү;

Федераль законда билгеләнгән тәртиптә реакция белдерүнең региональ дәрәҗәсен билгеләү.

Татарстан Республикасы Президенты шулай ук Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен дә җитәкли.»;

2) 9 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планнарын эшләү һәм раслау.»;

3) 10 статьяда:

а) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрне муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләргә кертү, гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын уздыру турында карарлар кабул итү һәм шушы чараларны уздыруны оештыру;»;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планнарын эшләү һәм раслау.»;

4) 19 статьяның беренче өлешендәге өченче абзацында «муниципаль берәмлек чикләрендә (территориясендә)» сүзләрен «муниципаль характердагы» сүзләренә алмаштырырга;

5) 21 статьяда:

а) беренче өлешкә «, оешмалар» сүзен өстәргә;

б) икенче өлешкә «, оешмалар» сүзен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2019 ел, 25 декабрь
№ 110-ТРЗ